**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге составына керүче Федот торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

**16.11.2022** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә. № 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2022 елның 16 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Сез 2023 елда Кадер авыл җирлегенең Федот торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картайган гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләрне хәл итү өчен тотуга ризамы:

- зиратта агачларны кисү».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 23 кеше кертелгән, 15 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен 15 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен тавыш бирүче булмады.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегенең Федот торак пунктында гражданнар җыены үткәнен, халык җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2023 елда Кадер авыл җирлегенең Федот торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картайган гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- зиратта агачларны кисү.» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында (Кадер авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Кадер авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Барсукова**